**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең Борындык торак пунктында**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«31» октябрь, 2019 № 1

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең Борындык торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ :

1. 2020 елда үзара салым акчаларын Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500(биш йөз) сум күләмендә алып барырга.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

а) авыл җирлеге территориясен төзекләнләндерү:
- Борындык авылындагы буаны ремонтлау, чистарту һәм төзекләндерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- урамнардагы яктырткычларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;
- һәйкәлләрне төзекләндерү, моның өчен материаллар сатып алу;

б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:
- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

г) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны беренчел янгын куркынычсызлыгы чарасы белән тәэмин итүне оештыру:
- янгын сүндерү машинасын ремонтлау һәм техник запчастьләр сатып алу.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Борындык авыл җирлеге
Кайбыч муниципаль районы
Татарстан Республикасы
Совет рәисе урынбасары Р. Р. Нигъмәтҗанова